МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ

№ 696/о

БОЕРЫК

«02» 06 2025

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Лениногорск-Чирмешән» автомобиль юлында инеш аша күперне реконструкцияләү, 77+557 км» линия объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын раслау турында

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 43, 45 һәм 46 статьялары, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында 77+557 км «Лениногорск-Чирмешән» автомобиль юлында инеш аша күперне реконструкцияләү, 77+557 км» линия объекты территориясен планлаштыру проектын һәм территориясен ызанлау проектын әзерләү турында» 2025 елның 20 гыйнварындагы 29/о номерлы боерыгы нигезендә, 2025 елның 28 мартыннан 2025 елның 24 апреленә кадәр уздырылган гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, боерык бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Лениногорск-Чирмешән» автомобиль юлында инеш аша күперне реконструкцияләү, 77+557 км» линия объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне ызанлау проектын расларга (кушымтада бирелә).

2. Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсенең көньяк-көнбатыш районнарны үстерү бүлегенә (А.С.Харитоновка) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге башлыгына ул үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрүне;

әлеге боерыкны «Татарстан Республикасы шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында ул басылып чыккан көннән алып 10 эш көне эчендә урнаштыруны;

әлеге боерык үз көченә кергән көннән алып биш эш көне эчендә «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен файдаланыла торган координаталар исемлеген үз эченә алган белешмәләрне электрон рәвештә җибәрүне;

әлеге боерыкны үз көченә кергән көннән җиде календарь көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны.

3. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга) дәүләт теркәвенә алу өчен әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Территорияләрне үстерү департаментының Агломерацияләрне үстерү идарәсе башлыгы С.А.Рыбаковка йөкләргә.

Министр урынбасары | Отдел контроля исполнения документов | В.Н.Кудряшев

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 02.06.2025 ел, № 696/о боерыгы белән расланды

# «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Лениногорск-Чирмешән» автомобиль юлында инеш аша күперне реконструкцияләү, 77+557 км» линия объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру проекты

2025

| Том № | Билгеләнеше | Атамасы | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| **Территорияне планлаштыру документациясе составы** | | | |
| **1 өлеш. Территорияне планлаштыру проектының төп (раслана торган) өлеше** | | | |
| 1 | 2269-24-ДПТ-ППТ | 1 бүлек. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеше. Кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары | (Китерелми) |
| | 2269-24-ДПТ-ППТ | 2 бүлек. Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә | 3 п., 4 п. китерелми |
| **2 өлеш. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материаллары** | | | |
| 2 | 2269-24-ДПТ-ППТ-МО | 3 бүлек. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар. График өлеше. | Китерелми |
| | 2269-24-ДПТ-ППТ-МО | 4 бүлек. Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар. Аңлатма язуы. | Китерелми |
| **3 өлеш. Территорияне ызанлау проектының төп (раслана торган) өлеше** | | | |
| 3 | 2269-24-ДПТ-ПМТ | 1 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше. | |
| | 2269-24-ДПТ-ПМТ | 2 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше. | 2 п., 3 п. китерелми |
| **4 өлеш. Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары** | | | |
| 4 | 2269-24-ДПТ-ПМТ-МО | 3 бүлек. Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. График өлеше. | Китерелми |
| | 2269-24-ДПТ-ПМТ-МО | 4 бүлек. Территорияне ызанлау проектын нигезләү материаллары. Аңлатма язуы. | Китерелми |

Взам. инв. №

Имза

Инв. № подл.

| Үзг. | К.са | Бит | № | Имза | Дата | 2269-24-ДПТ-ППТ | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Эшләде. | | Кадыйров | | [signature] | 03.2 | Территорияне планлаштыру документациясе составы | Стади | Бит |
| | | | | | | | | 1 |
| Н.контр. | | Потапова | | | 03.2 | | «Спецдорпроект» ЖЧЖ | |
| гип | | Тарасова | | | 03.25 | | | |

А4 формат

«СПЕЦДОРПРОЕКТ» ҖАВАПЛЫЛЫГЫ
ЧИКЛӘНГӘН ҖӘМГЫЯТЕ

СПЕЦДОРПРОЕКТ

Татарстан Республикасы, 420073, Казан ш.,
Кариев ур., 10 й., тел/факс: (843) 222-52-16,
e-mail: adsproekt@yandex.ru

# «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Лениногорск-Чирмешән» автомобиль юлында инеш аша күперне реконструкцияләү, 77+557 км» линия объектын урнаштыруны күздә тота торган территорияне планлаштыру проекты

1 өлеш. Территорияне планлаштыру проектының төп (раслана торган) өлеше

2269-24-ДПТ-ППТ

1 том.

Директор Тарасова Е.М.

2025

# ТОМНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ


| Билгеләнеше | Атамасы | Искәрмә |
|---|---|---|
| 2269-24–ДПТ–ППТ | ТОМНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ | 2-3 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 1 бүлек. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеше. | |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | Кызыл линияләр сызымы М 1: 500 | 4 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | Кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми) | 5 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | Линия объектын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең сызымы М 1:500 | 6 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | Урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең | 7 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 2 бүлек. Линия объектларын урнаштыру турында нигезләмә | |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 1. Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының, шулай ук линия объектларының атамасы, төп характеристикалары (категориясе, озынлыгы, проект куәте, үткәрү сәләте, йөк көчәнеше, хәрәкәт интенсивлыгы) һәм билгеләнеше | 8-9 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 2. Территорияләрендә линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, муниципаль округлар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге шәһәрләрнең җирлекләре, торак пунктлары, шәһәр эчендәге территорияләре исемлеге | 9-10 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 3. Линия объектын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми) | 10 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 4. Линия объектларының урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары | 11 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 5. Планлаштырыла торган урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керүче капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең ин чик параметрлары | 11 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 6. Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелә торган капиталь төзелешнең сакланып калучы объектларын (бинаны, | 12 |


| Үзг. | Киш.са | Бит | Док.№ | Имза | Дата | 2269-24–ДПТ–ППТ | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Эшләде | | Кадыйрова | | | 08.24 | ТОМНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ | Стадия | Бит | Битләр |
| | | | | | | | | 1 | 2 |
| Н.контр. | | Полякова | | | 08.24 | | «Спецдорпроект» ЖЧЖ | | |
| гип | | Соловьев | | | 08.24 | | | | |

Взам. инв.

Имза һәм дата

Инв. № подл.

| Билгеләнеше | Атамасы | Искәрмә |
|---|---|---|
| | корылманы, төзелеп бетмәгән объектларны), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документация нигезендә төзүгә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат | |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 7. Линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклап калу чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат | 12 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 8. Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат | 13-15 |
| 2269-24–ДПТ–ППТ | 9. Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат | 15-17 |

# 1 бүлек. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеше.




- границы территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки
- устанавливаемые красные линии

1, 2, 3, 4 ... – номера характерных точек устанавливаемых красных линий

- границы планируемых элементов планировочной структуры
- границы существующих элементов планировочной структуры

Согласовано

Взам. инв. N

Подпись и дата

Инв. N подл.

СПЕЦДОРПРОЕКТ

Формат А3

**Кызыл линияләрнең характерлы ноктулары координаталары исемлеге (китерелми)**

| Үзг. | Кул. | Бит | док.№ | Имза | Дата |
|---|---|---|---|---|---|
| Эшләде. | | | | | |
| Конт.н гип | | | | | |

2169-24-ДПТ-ППТ

Килештерелде

Имза һәм дата

Инв.№



- границы территории, в отношении которой осуществляется подготовка проекта планировки
- границы зон планируемого размещения линейных объектов

1, 2, 3, 4 ... – номера характерных точек границ зон планируемого размещения линейных объектов

Согласовано

Взам. инв. N

Подпись и дата

Инв. N подл.

СПЕЦДОРПРОЕКТ

Формат А3

# 2 бүлек. Линия объектын урнаштыру турындагы нигезләмә.

**Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының, шулай ук линия объектларының атамасы, төп характеристикалары (категориясе, озынлыгы, проект куәте, үткәрү сәләте, йөк көчәнеше, хәрәкәт интенсивлыгы) һәм билгеләнеше**

Объектның исеме: Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Лениногорск-Чирмешән» автомобиль юлында инеш аша күперне реконструкцияләү, 77+557 км».

Күпер III техник категорияле «Лениногорск - Чирмешән» автомобиль юлында урнашкан.

Линия объектының максаты: автомобиль транспортын һәм җәяүлеләрне үткәрү өчен хезмәт итүче автомобиль юлы күпере.

Озынлыгы: 0,087 км.

Үткәрү сәләте (проект куәте): сәгатенә 2100 берәмлек.

### 1.1 Йөк киеренкелеге һәм хәрәкәт интенсивлыгы

Проектлана торган участок буенча хәрәкәт интенсивлыгының үсүен түбәндәге факторлар билгели:

тартылу районы икътисадында базар мөнәсәбәтләрен үстерү;

автомобильләшү дәрәҗәсен алга таба арттыру.

2024 елга һәм перспективалы 2048 елга автотранспорт хәрәкәте составы һәм интенсивлыгы 1.1.1 нче таблицада китерелгән.

1.1.1 нче таблица

| т/с | Транспорт чарасы төре | Интенсивлык, тәүлегенә берәмлек | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2024 | | 2048 | |
| | | башлангыч | китерелгән | башлангыч | китерелгән |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | Җиңел автомобильләр, зур булмаган йөк машиналары (фургоннар) һәм тагылмалы һәм аннан башка бутән | 1038 | 1038 | 1637 | 1637 |
| 2 | Ике күчәрле йөк автомобильләре | 195 | 293 | 308 | 462 |
| 3 | Өч күчәрле йөк автомобильләре | 167 | 300 | 263 | 473 |
| 4 | Дүрт күчәрле йөк автомобильләре | 58 | 117 | 92 | 184 |

| т/с | Транспорт чарасы төре | Интенсивлык, тәүлеккә берәмлек | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2024 | | 2048 | |
| | | башлангыч | китерелгән | башлангыч | китерелгән |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 5 | Дүрт күчәрле автопоездлар (тагылмалы ике күчәрле йөк автомобиле) | 51 | 113 | 81 | 178 |
| 6 | Биш күчәрле автопоездлар (тагылмалы өч күчәрле йөк автомобиле) | 9 | 24 | 14 | 38 |
| 7 | Өч күчәрле иярле автопоездлар (ярымтагылмалы ике күчәрле иярле трактор) | 7 | 15 | 11 | 24 |
| 8 | Дүрт күчәрле иярле автопоездлар (ярымтагылмалы ике күчәрле иярле трактор) | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 9 | Биш күчәрле иярле автопоездлар (ярымтагылмалы ике күчәрле иярле трактор) | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 10 | Биш күчәрле иярле автопоездлар (ярымтагылмалы өч күчәрле иярле трактор) | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 11 | Алты күчәрле иярле автопоездлар | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 12 | Җиде һәм аннан да күбрәк күчәрле автомобильләр һәм башкалар | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 13 | Автобуслар | 45 | 135 | 71 | 213 |
| **Барлыгы:** | | **1570** | **2035** | **2477** | **3209** |

Урыннары үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле объектларның төп характеристикалары:

электр яктырту кабеленең озынлыгы 120 метр, көчәнеше 0,4 киловольт, үткәрү сәләте һәм егәрлеге 70 киловатт, 112 ампер. Электр энергиясен үткәргечләр буенча тапшыру яки бүлү өчен билгеләнгән. Саклау зонасы һәр якка икешәр метр;

»Таттелеком» ачык акционерлык җәмгыятенең абонент, телефон элемтә линиясе, озынлыгы 111 метр. Мәгълүмат сигналларын тапшыру өчен билгеләнгән. Саклау зонасы һәр якка икешәр метр.

## 2. Территорияләрендә линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге,

**Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, муниципаль округлар, шәһәр округлары исемлеге федераль әһәмияттәге шәһәрләр җирлекләре, торак пунктлары, шәһәр эчендәге территорияләре исемлеге**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Лениногорск-Чирмешән» автомобиль юлында инеш аша күперне реконструкцияләү, 77+557 км» линия объектын планлаштырып урнаштыру зонасы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Иске Үтәмеш авылы территориясендә билгеләнә.

## 3. Линия объектын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми)

Имза һәм дата

## 4. Линия объектларының урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми)

## 5. Планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керүче капиталь төзелеш объектларын төзүнең, реконструкцияләүнең рөхсәт ителгән чик параметрлары

Рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары билгеләнә торган линия объекты составына керүче капиталь төзелеш объектлары линия объектын планлаштырып урнаштыру зонасы чикләрендә юк.

## 6. Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелә торган капиталь төзелешнең сакланып калучы объектларын (бинаны, төзелешне, корылманы, төзелеп бетмәгән объектларны), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документация нигезендә төзүгә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыруга бәйле рәвештә тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Проектны әзерләү вакытында төзелә торган территорияне планлаштыру, шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзүгә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектлары әлеге проектта юк.

Линия объектын планлаштырып урнаштыру зонасы чикләрендә гамәлдәге элемтә челтәрләре һәм электр яктырту кабеле урнашкан, алар яңадан урнаштырылачак. Линия объектын урнаштыру капиталь төзелеш объектларына тискәре йогынты ясамаячак.

«Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыятенең төзелеш эшләрен башкару зонасына эләгүче элемтә челтәрләре норматив документлар һәм 14.11.2024 ел, № 9149-12 Техник шартлар таләпләренә туры китереп үзгәртеп корыла. Элемтә кабеленең саклау зонасы һәр якка ике метр.

Электр яктырту кабелен үзгәртеп кору норматив документлар һәм 22.11.2024 ел, № 7675 Техник шартлар таләпләренә туры китереп башкарыла. Электр яктырту кабеленең саклау зонасы һәр якка икешәр метр.

## 7. Линия объектларын урнаштыруга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклап калу чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 06.08.2024 ел, № 01-02/4319 хаты нигезендә төзелеш территориясендә мәдәни мирас объектлары юк.

## 8. Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

### 8.1 Атмосфера һавасын саклау гамәлләре

Төзелеш чорында атмосфера һавасын саклау буенча төп чаралар булып түбәндәгеләр тора:

эшләрне этаплап, кыска-кыска юл белән башкару, бу техниканы таратырга ярдәм итә һәм бер үк вакытта атмосфера һавасына йөкләнешне киметә;

җитештерүнең барлык машиналары һәм механизмнары эшкәртелгән газларны каталитик нейтрализаторлар белән җиһазландырыла;

автомашиналарның һәм махсус техниканың агулы һәм төтенле газларын контрольдә тоту;

коелучан йөк ташучы автосамосваллар һәм бортлы машиналар алмаштырыла торган махсус тентлар белән җиһазландырылырга тиеш;

тузан бүлеп чыгаруны киметү өчен тузан чыгаручы материалларны бушату алдыннан су

белән чылату; атмосфераны пычратучы матдәләр күләмен киметү өчен төзелештә электр приводлы механизмнар куллану;

төзелеш мәйданчыгы территориясендә калдыкларны һәм төзелеш чүп-чарын яндыру тыела;

лак-буяу материаллары, сыек нигездәге су үткәрми торган материаллар, мастиклар төзелеш мәйданчыгына герметик махсус савытта  китерелергә һәм сакланырга тиеш;

күчергәндә тузан барлыкка килә торган коелучан материаллар ябык бүлмәләрдә капчыкларга төреп яисә ачык мәйданчыклардагы махсус бункерларда сакланырга тиеш;

төзелеш чорында һавадагы зарарлы матдәләрнең микъдарын тикшереп торырга.

Файдалану чорында ягулыкның яну продуктлары белән пычрану дәрәҗәсен киметү һәм юлда пычрану зонасының киңлеген киметү максатында түбәндәгеләрне эшләргә кирәк:

транспорт агымының өзлексез һәм тигез хәрәкәтен хәрәкәтне оештыру чаралары белән тәэмин итәргә;

юлның машина йөрү өлешен автомобильләр хәрәкәте тизлегенең нигезсез үзгәрүенә юл куймаслык хәлдә тотарга;

юл буендагы агач-куак үсемлекләрен кисүгә юл куймаска.

### 8.2 Җир ресурсларын һәм туфрак катламын саклау һәм алардан нәтиҗәле файдалану чаралары

Җирләрне саклау максатларында (механизмнар хәрәкәт иткәндә) түбәндәге чаралар каралган:

төзелеш эшләрен бары тик бүлеп бирелгән полосада гына алып бару гамәлдәге яшеллекләрнең механик зарарлануыннан саклап калу максатыннан башкарыла;

төзелеш-монтаж эшләрен башкару, машиналар һәм механизмнар хәрәкәте, материалларны җитештерү проектында каралмаган урыннарга туплау һәм саклау тыела;

склад мәйданчыклары җир өсте суларыннан вакытлыча су агызу җайланмалары белән сакланырга тиеш;

коелучан материаллар ябык бүлмәләрдә капчыкларга төрелгән килеш яисә ачык мәйданчыклардагы махсус бункерларда сакланырга тиеш;

лак-буяу материаллары, сыек нигездәге су үткәрми торган материаллар, мастиклар төзелеш мәйданчыгына герметик махсус савытта китерелергә һәм сакланырга тиеш;

монтаж эшләренең барлык этапларында да объект территориясендәге агынтыны үзгәртү, аны төзелеш калдыклары белән чүпләү, ягулык-майлау материалларын агызу, эшкәртелгән майларны агызу рөхсәт ителми;

мәйданчыкта барлыкка килгән җитештерү һәм көнкүреш агынтылары эшләрне башкару проектында каралган тәртиптә чистартылырга һәм сусызландырылырга тиеш.

Төзелеш-монтаж эшләре тәмамланганнан соң мәйданчык территориясе чүп-чардан чистартылырга тиеш.

Шулай итеп, чаралар комплексын үтәгәндә, проект эшләрен башкарганда да, төзелеш һәм эксплуатацияләү процессында да проектлана торган объектның әйләнә-тирә мохиткә йогынтысы минимумга кадәр киметелде.

Туфракка тискәре йогынты ясамас өчен, төзелеш вакытында туфракның өске уңдырышлы катламын алып ташларга кирәк. Җир эшләрен башкарганда туфракның потенциаль уңдырышлы катламын потенциаль уңдырышлы токымнардан аерым алырга кирәк.

Эш барышында шунда ук файдаланылмаган туфракның уңдырышлы катламы буртларга салынырга тиеш. Әгәр туфракның уңдырышлы катламын саклау срогы ике елдан артып китсә, буртның өслегенә һәм аның сөзәклекләренә күпьеллык үләннәр чәчелергә тиеш. Бурт сөзәклекләрен гидротехник ысул белән чәчү рөхсәт ителә. Туфракның уңдырышлы катламы буртларда 20 ел саклана ала. Буртлар өчен авыл хуҗалыгы өчен яраксыз яисә аз продуктлы җирләр бирелергә тиеш, аларда су басу, тозлану һәм сәнәгать калдыклары, каты әйберләр, таш, вак таш, чуер таш, төзелеш чүп-чарлары белән пычрану мөмкинлеге юк ителә.

Туфракның уңдырышлы катламын салу бары тик елның җылы вакытында гына башкарылырга тиеш (нормаль дымлылык һәм машиналар үтү өчен грунт җитәрлек күтәрү сәләте булганда). Моның өчен туфракның уңдырышлы катламын күчереп һәм тигезләп, аркылы йөрешле бульдозерлар файдаланыла.

### 8.3 Эксплуатацияләү чорында җир өсте һәм җир асты суларын саклау гамәлләре

Җир өсте һәм җир асты суларын пычрату мөмкинлеген булдырмау өчен түбәндәге чаралар проектланды:

елганың су саклау зонасыннан уза торган автомобиль юлы участогында юл өслегеннән һәм җир асты суларына яңгыр сулары йогынтысын булдырмау өчен проектта яңгыр суларын һәм кар суларын күпернең уң һәм сул якларында проектланган чистарту корылмаларына агызып җыю, чистартылган агынты суларны туфракның тирән катламнарына фильтрлау каралган;

проектлана торган объектлар территориясен колачлый торган су саклау, санитар саклык һәм яр буе зоналарында хуҗалык эшчәнлеген алып бару режимын үтәү;

бүлеп бирелгән полосаны чиста һәм тәртиптә тоту;

юл өслекләрен вакытында ремонтлау, кышкы чорда кар җыю һәм чыгару вакытында башкарыла.

## 9. Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат

Проектлана торган объект атом энергиясен файдалану объектларына, куркыныч җитештерү объектларына, аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы, уникаль объектларга, оборона һәм иминлек объектларына Россия Федерациясе законнарында билгеләнә торган критерийлар буенча керми, атап әйткәндә:

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48[1] статьясы критерийлары буенча объекты аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы һәм уникаль объектлар рәтенә керми;

«Хәвефле җитештерү объектларының сәнәгать куркынычсызлыгы турында» 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты һәм 1 кушымтасы критерийлары буенча объект хәвефле җитештерү объектлары категориясенә керми.

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 12.11.2024 ел, № 6761/ТЗ-3-5 хаты нигезендә, линия объекты урнашачак проектлана торган территория гражданнар оборонасы төркемнәренә керми. Территориядә гражданнар оборонасы категориясенә кертелгән оешмалар юк. Әлеге территория химик зарарлану, җимерелү, радиоактив зарарлану һәм коточкыч су басу ихтималы булган зоналарга эләкми. Оборонаның саклау корылмаларын төзү таләп ителми.

Инженер-геологик эзләнүләр нәтиҗәләре нигезендә эзләнүләр үткәрү вакытында участокта эрозия-сөзәк процессларның нинди дә булса күренешләре ачыкланмаган.

Эзләнүләр участогында елга үзәненең битләре томаланган, юылулар күзәтелми. Гамәлдәге куркыныч инженер-геологик процессларны ачыклау һәм карст-суффозион процессларның куркыныч дәрәҗәсен бәяләү өчен, карстның өске күренешләрен һәм гамәлдәге башка инженер-геологик процессларны ачыклау максатында эшләр участогына маршрут тикшерүе үткәрелде. Визуаль күзәтүләр буенча (объектны рекогносцировкалау) тикшерелә торган территориядә упкыннар, бүрәнкәләр булу кебек карст процесслары күренешләре юк. Эзләнүләр участогының инженер-геологик киселеше бөтен ачылган егәрлеккә капланма калынлык хасил итүче балчыклы токымнардан тора, бу исә җир өслегендә карст барлыкка килү ихтималыннан саклауны тәэмин итә. Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә, геологик төзелешенә (күрсәтелгән инженер-геологик шартларга) туры китереп, тикшерелә торган участок өске карст процессларының чагылыш куркынычы буенча тотрыклылыкның VI категориясенә карый – территория тотрыклы.

Табигый катаклизмнар һәм техноген аварияләр булмаганда инженер-геологик шартларда җитди үзгәрешләр фаразланмый.

Проектлана торган объект урнашкан районның табигый-климат үзенчәлекләрен исәпкә алып, җир тетрәүләр, шуышулар кебек табигый характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу ихтималы бик аз. Түбәндәге метеорологик процесслар килеп чыгу ихтималы бар: яңгыр, бик көчле яңгыр, бик көчле кар, көчле җил, эре боз, чыбыкларда бик көчле бозлавык, көчле томан, көчле буран.

Төзелештә кулланыла торган материаллар янучан булмаганнарга керә. Материалларны янучан булмаганнар төркеменә керткән очракта, аларның янгын куркынычын бәяләү буенча алга таба гамәлләр башкарылмый. Автомобиль юлының машина юлы асфальт-бетоннан түшәлгән. Асфальтобетон янмый торган булып тора, авыр кабына һәм яна торган продуктларының агулылыгы буенча аз дәрәҗәдә куркыныч материал.

Янгын сүндерү «Янгынга каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча 11 отряды» ФДКУ 135 нче янгын-коткару часте дежур бригадасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Эш режимы – тәүлек буе.

Урнашу урыны: 423100, Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Чирмешән авылы, Титов урамы, 6 йорт.

Шулай ук Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 26.09.2024 ел, № 5733/ТЗ-3-5 хаты нигезендә (Территорияне планлаштыру проектын нигезләү материалларының 10 нчы кушымтасында бирелгән) «Гражданнар оборонасы чаралары, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү чаралары исемлеге» бүлеген эшләргә кирәкми.

Инженер-гидрометеорологик һәм инженер-геологик тикшеренүләр нигезендә проектлана торган объектны су басуга дучар итмиләр, куркыныч гидрологик һәм инженер-геологик процесслар һәм күренешләр юк. Әлеге территория химик зарарлану, җимерелү, радиоактив зарарлану һәм коточкыч су басу ихтималы булган зоналарга эләкми. Димәк, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләрнең чикләре юк.

«СПЕЦДОРПРОЕКТ» ҖАВАПЛЫЛЫГЫ
ЧИКЛӘНГӘН ҖӘМГЫЯТЕ

Татарстан Республикасы, 420073, Казан ш.,
Кариев ур., 10 й., тел/факс: (843) 222-52-16,
e-mail: adsproekt@yandex.ru

# Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Лениногорск-Чирмешән» автомобиль юлында инеш аша күперне реконструкцияләү, 77+557 км» линия объектын урнаштыруны күздә тота

3 өлеш. Территорияне ызанлау проектының төп (раслана торган) өлеше

2269-24-ДПТ-ПМТ

3 том.

Директор Тарасова Е.М.

2025

# ТОМНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

| Билгеләнеше | Атамасы | Искәрмә |
|---|---|---|
| 2269-24–ДПТ-ПМТ | ТОМНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ | 2 |
| 2269-24–ДПТ-ПМТ | 1 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. График өлеше. | |
| 2269-24–ДПТ-ПМТ | Территорияне ызанлау сызымы | 3 |
| 2269-24–ДПТ-ПМТ | 2 бүлек. Территорияне ызанлау проекты. Текст өлеше. | |
| 2269-24–ДПТ-ПМТ | 1. Барлыкка килә торган җир кишәрлекләре исемлеге | 4 |
| 2269-24–ДПТ-ПМТ | 2. Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми) | 5 |
| 2269-24–ДПТ-ПМТ | 3. Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре турында белешмәләр. 3.1 нче таблица | 6-7 Китерелми |
| 2269-24–ДПТ-ПМТ | 4. Линия объекты составында проектлана торган линия объектларын һәм капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән барлыкка килә торган җир кишәрлекләреннән, шулай ук линия объектлары составына керә торган линия объектлары һәм капиталь төзелеш объектлары биләгән гамәлдәге җир кишәрлекләреннән территорияне планлаштыру проекты нигезендә рөхсәт ителгән файдалану төре | 7 |

Имза һәм · Взам. инв. № · Инв. № подл.

| Үзг. | Киш-саны | Бит | Док № | Имза | Дата |
|---|---|---|---|---|---|
| Эшләде | | Кадыйрова | | | 09.24 |
| Н.контр. | | Потапова | | | 09.24 |
| гип | | Тарасова | | | 09.24 |

2269-24–ДПТ–ПМТ

ТОМНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

| Стадия | Бит | Битләр |
|---|---|---|
| | 11 | |

«Спецдорпроект» ҖЧҖ

# 4 бүлек. Территорияне ызанлау проекты.
# График өлеше.




— установливаемые красные линии

— границы планируемых элементов планировочной структуры

— границы существующих элементов планировочной структуры

— границы образуемых и (или) изменяемых земельных участков

ЗУ-1(1) — условные номера образуемых и (или) изменяемых земельных участков

— границы водного объекта

Согласовано

Взам. инв. N

Подпись и дата

Инв. N подл.

СПЕЦДОРПРОЕКТ

Формат А3

# 2 бүлек. Территорияне ызанлау проекты.
# Текст өлеше.

## 1. Барлыкка килә торган җир кишәрлекләре исемлеге

Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең шартлы номерларын, барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары номерларын, җир кишәрлекләренең кадастр номерларын, барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең мәйданнарын, җир кишәрлекләрен барлыкка китерү ысулларын үз эченә алган барлыкка китерелә торган җир кишәрлекләре исемлеге 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында «Лениногорск-Чирмешән» автомобиль юлында инеш аша күперне реконструкцияләү, 77+557 км» объектын урнаштыру күздә тотыла торган барлыкка китерелә торган, гомуми файдаланудагы территорияләргә яисә гомуми файдаланудагы мөлкәткә кертеләчәк җир кишәрлекләренең мәйданы, исемлеге, шул исәптән аларны булдыруның мөмкин булган ысуллары турында белешмәләр.

| п/п | Условные номера образуемых земельных участков | Номера характерных точек образуемых земельных участков | Кадастровый номер земельного участка | Площадь образуемых земельных участков, кв.м | Способ образования земельного участка | Сведения об отнесении (неотнесении) образуемых земельных участков к территории общего пользования | Категория земель и вид разрешенного использования исходного земельного участка | Установить категорию земель / вид разрешенного использования / адрес земельного участка | Целевое назначение лесов, вид (виды) разрешенного использования лесного участка, количественные и качественные характеристики лесного участка, сведения о нахождении лесного участка в границах особо защитных участков лесов | Условные номера, кадастровые номера образуемых земельных участков, в отношении которых предполагается их резервирование и (или) изъятие для государственных или муниципальных нужд, их адреса | Перечень кадастровых номеров существующих земельных участков, на которых линейный объект может быть размешен на условиях сервитута, публичного сервитута, их адреса или описание местоположения, перечень и адреса расположенных на таких земельных участках объектов недвижимого имущества |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | ЗУ1(1) | н1, н2, н3, н4, н5, н6, н7, н8, н9, н10, н11, н12, н13, н14, н15, н1 | 16:41:000000 | 693 | Образование земельного участка из земель, находящихся в государственной или муниципальной собственности | Образуемый земельный участок относится к территории общего пользования | Категория земель не установлена/ Вид разрешенного использования не установлен | Земли населённых пунктов/ Земельные участки (территории) общего пользования Российская Федерация, Республика Татарстан, Черемшанский муниципальный район, Староутямышское сельское поселение, с. Старый Утямыш | Лесные участки отсутствуют | Образуемые земельные участки, в отношении которых предполагается их рехервирование и (или) изъятие для гос. или муниципальных нужд, отсутствуют | Земельные участки , на которых линейный объект может быть размещен на условиях сервитута, публичного сервитута, отсутствуют |
| 2 | ЗУ1(2) | н16, н17, н18, н19, н20, н21, н22, н23, н24, н25, н26, н27, н28, н29, н30, н16 | 16:41:000000 | 655 | Образование земельного участка из земель, находящихся в государственной или муниципальной собственности | Образуемый земельный участок относится к территории общего пользования | Категория земель не установлена/ Вид разрешенного использования не установлен | Земли населённых пунктов/ Земельные участки (территории) общего пользования Российская Федерация, Республика Татарстан, Черемшанский муниципальный район, Староутямышское сельское поселение, с. Старый Утямыш | | | |
| ИТОГО: | | | | 1348 | | | | | | | |

Килештерелде

Имза һәм дата

Инв.№ под

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2269-24-ДПТ-ПМТ |
| Үзг. | Кул. | Бит | док.№ | Имза | Дата | |
| Эшләде | | Кадыйрова | | | 09.24 | Аңлатма язуы |
| Н.контр. | | Потапова | | | 09.24 | |

| Стадия | Бит | Битләр |
|---|---|---|
| | 1 | 4 |

«Спецдорпроект» ЖЧҖ

## 2. Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге

Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге 2 нче таблицада бирелгән.

2 нче таблица. Барлыкка килә торган җир кишәрлекләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми).

## 3. Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләре турында белешмәләр

Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территориянең чикләре Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авылында урнашкан. Ызанлау проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге 3.1 нче таблицада бирелгән.

3.1 нче таблица МСК-16 координаталар системасында территория чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (китерелми).

Взам.инв №
Имза һәм дата
Инв.№ под

## 4. Линия объекты составында проектлана торган линия объектларын һәм капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән барлыкка килә торган җир кишәрлекләреннән, шулай ук линия объектлары составына керә торган линия объектлары һәм капиталь төзелеш объектлары биләгән гамәлдәге җир кишәрлекләреннән территорияне планлаштыру проекты нигезендә рөхсәт ителгән файдалану төре

Линия объекты составында проектлана торган линия объектларын һәм капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен билгеләнгән барлыкка килә торган ЗУ-1(1) һәм ЗУ-1(2) җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре – гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре (территорияләр).

Булган җир кишәрлеге – чикләнмәгән дәүләт милке, булган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән.

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Взам.инв № | | | | | |
| Инв.№ под | | | | | |

Үзг. Күл. Бит Док.№ Имза
Дата